ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында" 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле $6^1$ статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«$6^1$ статья. **Мәдәни мирас объектларын саклап калуда ихтыярый ярдәм итүчеләрнең (волонтерларның) катнашуы**

Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын яисә ачыкланган мәдәни мирас объектын саклап калу эшләренең аерым төрләрен башкаруда ихтыярый ярдәм итүчеләр (волонтерлар) катнашырга мөмкин. Ихтыярый ярдәм итүчеләрнең (волонтерларның) Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын яисә ачыкланган мәдәни мирас объектларын саклап калу эшләрендә катнашу үзенчәлекләре, шулай ук мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча эшләрнең күрсәтелгән затлар катнаша ала торган төрләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Федераль закон нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 27 февраль
№ 3-ТРЗ